ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘЗКӘЙ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

42361, Кәзкәй авылы,
Беренче май ур., 2 а нчыйорт.
Тел.3-44-46

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЗКЕЕВКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423761, село Казкеево,
ул. Первомайская,дом 2а,
Тел. 3-44-46

**РЕШЕНИЕ** — **КАРАР**

18.12.2024 — № 29

Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлеге Советының
«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 24 маендагы 11 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында " 12.07.2024 ел, № 176-ФЗ Федераль законга (2024 елның 12 декабренә үзгәрешләр кертеп), Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Кәзкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Кәзкәй авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 24 маендагы 11 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның 14 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларына карата салым ташламасы бирелми, мондый салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннарыннан тыш, һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2_1 бүлегендә урнашкан урыннар моңа керми.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә урнаштырырга.

Актаныш муниципаль районы
Кәзкәй авыл җирлеге Совет рәисе — Р.Р.Шайхуллин